| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**12.07.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 208** |

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 373 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларны һәм вакантлы идарә вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында (сайлау комиссияләре аппаратларында) муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфалар һәм вакантлы идарә итү вазыйфаларына кадрлар резервын формалаштыру буенча үзара хезмәттәшлекне оештыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарә вазыйфаларын һәм вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервы турында» гы 373 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия турында нигезләмә Зеленодольск муниципаль районы Советы тарафыннан раслана. Комиссиянең персональ составы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.»;

10 пунктта «оештыру бүлеге» сүзләрен «кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3) 32 пунктның беренче абзацында «оештыру бүлеге» сүзләрен «кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4) 45 пунктның икенче абзацында «оештыру бүлеге» сүзләрен «кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы ,**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**